**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 март № 153

г. Казань

Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнаштыру өчен юллама бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм балалар оешмалары эшчәнлеге турында һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны аларга урнаштыру хакында» 2014 ел, 24 май, 481 нче карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнаштыру өчен юллама бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 15 еннән дә соңга калмыйча, ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган медицина оешмаларында, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларында буш урыннар булу турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мәгълүмат кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\153.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 март, 153 нче карары белән расланды

Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнаштыру өчен юллама бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына (алга таба – ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешма) вакытлыча урнаштыру өчен опека һәм попечительлек өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан юллама бирү процедурасын җайга салу максатларында эшләнде.

2. Ата-аналары, уллыкка-кызлыкка алучылары, опекуннары (попечительләре) нигезле сәбәпләр (шул исәптән эш урыны, даими керем чыганагы булмау, яшәү өчен яраклы торак урыны булмау, озак дәвалау таләп иткән госпитальләштерү, авыру һ.б.) буенча балигъ булмаганнарга мөнәсәбәтле үз вазыйфаларын үти алмаган гаиләләрдән булган балалар (алга таба – балигъ булмаган бала) ятим балалар өчен оешмада вакытлыча урнаштырыла ала.

3. Юллама биргәндә вәкаләтле орган 1995 ел, 29 декабрь, 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба – Гаилә кодексы), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм балалар оешмалары эшчәнлеге турында һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны аларга урнаштыру хакында» 2014 ел, 24 май, 481 нче карары белән расланган Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм балалар оешмалары эшчәнлеге турында һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны аларга урнаштыру хакында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) нигезендә эш итә.

4. Балигъ булмаган баланы ятим балалар өчен оешмага вакытлыча урнаштыру вакыты дүрт айдан күбрәк була алмый (балигъ булмаган баланың ата-аналары, уллыкка-кызлыкка алучылары, опекуннары (попечительләре) озак дәвалануга бәйле стационар дәвалануда булган очраклардан тыш) һәм опека һәм попечительлек органы карары буенча бер тапкыр күп дигәндә ике айга озайтыла ала.

5. Юллама алу максатларында, опека һәм попечительлек органы Нигезләмәнең 15 нче пунктындагы «а» – «ж», «и» пунктчаларында күрсәтелгән документлар кертелгән көннән 20 календарь көне эчендә Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

1) законлы вәкиле булган баланы ятим балалар өчен оешмага вакытлыча урнаштыру өчен юллама бирү турында әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада

бирелгән форма буенча үтенечнамә, һәм анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

баланы ятим балалар өчен оешмага вакытлыча урнаштыруның сәбәпләре;

әлеге оешма гамәлгә ашыра торган эшчәнлек һәм күрсәтә торган хезмәтләр төрләрен, шулай ук баланы карап тоту, тәрбияләү һәм белем бирү шартларын, баланың ихтыяҗларын һәм сәламәтлек торышын исәпкә алып, баланы вакытлыча урнаштырырга мөмкин булган ятим балалар өчен оешма (оешмалар);

10 яшькә җиткән баланың фикере;

2) Нигезләмәнең 15 нче пунктындагы «а» – «ж», «и» пунктчаларында күрсәтелгән документлар.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртү очракларын һәм үзенчәлекләрен билгели торган башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документлар Министрлыкка кертелгән көннән соң бер эш көне эчендә Министрлык:

аларны карап тикшерә;

Гаилә кодексының 155.1 статьясындагы 2 нче пунктта каралган нигезләр булганда, әлеге оешма гамәлгә ашыра торган эшчәнлек һәм күрсәтә торган хезмәтләр төрләрен, шулай ук баланы карап тоту, тәрбияләү һәм белем бирү шартларын, баланың ихтыяҗларын һәм сәламәтлек торышын исәпкә алып, бала вакытлыча урнаштырылырга тиеш булган ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешманы билгеләү турында карар кабул итә, әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны керткән опека һәм попечительлек органына бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча юллама бирә һәм әлеге Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча юлламалар бирүне теркәү журналына язма кертә;

Гаилә кодексының 155.1 статьясындагы 2 нче пунктта каралган нигезләр булмаса, әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны керткән опека һәм попечительлек органына юллама бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә;

опека һәм попечительлек органына әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны кире кайтара.

6. Юллама аны биргән көннән соң 10 календарь көне эчендә гамәлдә була.

7. Ятим балалар өчен оешма, баланы урнаштырганнан соң, өч көн эчендә әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча законлы вәкиле булган баланы ятим балалар өчен оешмага вакытлыча урнаштыру турында Министрлыкка раслама кертә.

8. Юлламаның күчермәсе һәм әлеге Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешманың球 распарламасы Министрлыкта саклана.

Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнаштыру өчен юллама бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Министрлыкка

Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына законлы вәкилләре булган баланы вакытлыча урнаштыру турында
ҮТЕНЕЧНАМӘ

______________________________________________________________________,
(опека һәм попечительлек органы исеме)

______________________________________________________________________
(ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмага баланы вакытлыча урнаштыру сәбәпләрен күрсәтергә)

__________________________________________________________ бәйле рәвештә,

______________________________________________________________________
(баланың Ф.И.Ат.и., туган көне)

______________________________________________________________________
(ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешма (оешмалар) исеме)

__________________________________________________________________
урнаштыру өчен юллама бирүне сорый.

10 яшькә җиткән баланың фикере теркәлә.

Опека һәм попечительлек
органы җитәкчесе _____________ _________________
(вазыйфасының тулы исеме) (имза) (Ф.И.Ат.и.)

____ _________________ 20__ ел. М.У.

Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнаштыру өчен юллама бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына законлы вәкилләре булган баланы вакытлыча урнаштыру өчен
ЮЛЛАМА

| | | |
|---|---|---|
| _____ ___________ **ел,** ______<br>**ЮЛЛАМА**<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы<br>_________________________________ җибәрә<br>(ятим балалар өчен оешма исеме)<br><br>Фамилиясе ______________________________<br>Исеме ________________________________<br>Атасының исеме _________________________<br>Туган көне һәм урыны ____________________<br>________________________________________<br><br>Белем маршруты: _______________________<br>________________________________________ | _____ ___________ **ел,** ______<br>**ЮЛЛАМА**<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы<br>_________________________________ җибәрә<br>(ятим балалар өчен оешма исеме)<br><br>Фамилиясе ______________________________<br>Исеме ________________________________<br>Атасының исеме _________________________<br>Туган көне һәм урыны ____________________<br>________________________________________<br><br>Белем маршруты: _______________________<br>________________________________________ | **ХӘБӘРНАМӘ**<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына кайтарылырга тиеш<br>_________________________________<br>(ятим балалар өчен оешма исеме)<br><br>_________________________________<br>(дата)<br><br>түбәндәге балигъ булмаган бала килүе турында хәбәр итә:<br>Фамилиясе ________________________<br>Исеме ____________________________<br>Атасының исеме ____________________<br>Туган көне һәм урыны _______________<br>__________________________________ |

| | | |
|---|---|---|
| Ятим балалар өчен оешмага җибәрү сәбәбе:<br><br>Әнисе ________________________________<br>Әтисе ________________________________<br>Баланың килгән урыны<br>____________________________________<br>Балигъ булмаган абый-энеләре һәм апа-сеңелләре турында мәгълүмат:___________________<br>____________________________________<br>____________________________________<br>Документларны рәсмиләштерү: билгеләнгән таләпләргә туры килә | Ятим балалар өчен оешмага җибәрү сәбәбе:<br><br>Әнисе ________________________________<br>Әтисе ________________________________<br>Баланың килгән урыны<br>____________________________________<br>Балигъ булмаган абый-энеләре һәм апа-сеңелләре турында мәгълүмат: __________________<br>____________________________________<br>____________________________________<br>Документларны рәсмиләштерү: билгеләнгән таләпләргә туры килә | Белем маршруты: ____________________<br>____________________________________<br><br>Түбәндәге документлар кабул ителде:<br>____________________________________<br>____________________________________<br>____________________________________ |
| Министр урынбасары<br>____________________________________<br>(имзасы) (Ф.И.Ат.и.)<br><br>М. У. | Министр урынбасары<br>____________________________________<br>(имзасы) (Ф.И. Ат.и.)<br><br>М. У.<br><br>Таләп ителә торган докуменлар булганда юллама 10 көн эчендә гамәлдә | Ятим балалар өчен оешма директоры:<br>____________________________________<br>(имзасы) (Ф.И. Ат.и.)<br><br>М. У.<br><br>________________________________<br>(хәбәрнамәне җибәрү датасы) |

Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнаштыру өчен юллама бирү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнаштыру өчен юлламалар бирүне
ТЕРКӘҮ ЖУРНАЛЫ

| Юлламаның саны, бирү датасы | Баланың Ф.И.Ат.и. | Баланың туган көне | Баланың фактта урнашкан урыны адресы | Баланың законлы вәкилләре турында мәгълүматлар | Ятим балалар һәм ата-ана кайгырту-ыннан мәхрүм калган балалар өчен оешма исеме | Юлламаны биргән вәкаләтле орган җаваплы хезмәткәре, Ф.И.Ат.и., имзасы | Юлламаны кабул итеп алган опека һәм попечительлек органы җаваплы хезмәткәре, Ф.И.Ат.и., имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |